ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БОЕРГАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

25 апрель 2018ел № 7

"Гражданнарның беренчел янгын куркынычсызлыгы
чараларын тәэмин итүдә, шул исәптән
ирекле янгын саклау эшчәнлегендә катнашу
формаларын билгеләү турында»

"Янгын куркынычсызлыгы турында" 21.12.1994 ел, № 69-ФЗ Федераль закон, "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 18.10.2007 ел, № 230-ФЗ Федераль Закон, "ирекле янгын саклау турында" 06.05.2011 ел, № 100-ФЗ Федераль закон, "Татарстан Республикасында ирекле янгын саклау турында" 01.08.2011 ел, № 48-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге территориясендә ирекле янгын саклау эшчәнлеген оештыру максатларында

КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге территориясе ирекле янгын сүндерү эшчәнлеге турында Нигезләмәне расларга, 1 нче кушымта нигезендә.
2. Ирекле янгын дружиналары (командалар) янгын сүндерү отряды төзергә һәм беренчел чаралар белән җиһазландырылган Корылманы булдырырга
3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында халыкка җиткергә
4.Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
5. Әлеге Нигезләмәне 2018 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Боерган авыл җирлеге башлыгы З.И.Камилҗанов